ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ТИМЯШЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ТИМӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е КАРАР

2019 елның 25 сентябре №15

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендәге 10 номерлы карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Федераль мәгълүмат адреслы система турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2-10 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендәге 10 номерлы карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

**а) 1.5 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«адрес-Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезендә структуралаштырылган һәм үз эченә шул исәптән урам-юл челтәре элементының һәм (яки) планлаштыру структурасы элементының атамасы (кирәк булганда), шулай ук адресация объектының санлы һәм (яки) хәреф-цифрлы билгеләнешен ала торган адресация объектының урнашу урыны тасвирламасы»;

**б) 1.5 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

“объектның адресы-капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект».

2.Әлеге карарны Тимәш авылындагы мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, гражданнарга уңайлы урыннарда урнаштырырга

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
Башлыгы Р.М.Сираев